КИЛЕШЕНГӘН:
балалар белән эш буенча
директор урынбасары
_______________ Р. Н. Каюмова
«24» август 2020 ел

РАСЛЫЙ:
«ҮКС» МБУ директоры
_______________ В.М. Гайнуллина
«24» август 2020 ел

**«Гаиләмнең яраткан китабы» шәһәркүләм бәйгесенең**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

**1. Гомуми нигезләмә**

1.1 Бу нигезләмә «Гаиләмнең яраткан китабы» (алга таба – Бәйге) шәһәркүләм бәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2 Бәйгенең оештыручысы – Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы филиалы.

**2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары**

2.1 Бәйгенең төп максаты – яшь буында татар теленә һәм китап укуга кызыксыну уяту.

2.2 Бәйгенең бурычлары:

- татар әдәбиятына игътибарны көчәйтү;
- әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне барлау, таныту һәм сәләтләрен үстерү;
- гаилә белән китап уку традицияләрен торгызу;
- китапханәләрдә китап укучы яшьләр санын арттыру.

**3. Бәйгедә катнашучылар**

3.1 Бәйгедә 11- 15 яшьтәге теләге булган һәркем катнаша ала.

**4. Бәйгенең шартлары**

4.1 Бәйгедә катнашучылар 2020 елның 1 сентябреннән 2020 елның 30 сентябренә кадәр 12нче санлы китапханәнең электрон почтасына үзләренең татарча язмаларын юллый.

4.2 Бәйгедә катнашу түләүсез.

4.3 Бәйгедә катнашу Бәйге шартлары белән килешүне аңлата.

**5. Бәйгегә җибәрелүче эшләргә таләпләр**

5.1 Бәйгегә китап укучының гаиләсендә яратып укыла торган берәр китапка багышланган язмасы (эссе) кабул ителә.

5.2 Эссе татар телендә, татар китабы турында булырга тиеш.

5.3 Материал күләме А-4 форматындагы 1 басма биттән ким булырга, 2 басма биттән (шрифт үлчәме – 14; ара интервалы - 1,5; поля - 2 см;) артмаска тиеш.

**6. Уздыру этаплары**

6.1 2020 елның 1 сентябреннән 2020 елның 30 сентябренә кадәр уздырыла

6.2 1 нче этап: 01.09.2020–26.09.2020 – эшләрне кабул итү.

6.3 2 нче этап: 28.09.2020 -29.09.2020– нәтиҗәләр ясау.

6.4 3 нче этап 30.09.2020 – Дипломнар тарату.

**7. Эшләрне бәяләү критерийлары**

7.1 Бәйге эшләрен бәяләү 5 баллы система буенча уздырыла. Йомгаклау нәтиҗәсе балларны кушу юлы белән ирешелә.

7.2 Бәйге эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

- күрсәтелгән темага туры килү;
- оригинальлек һәм мөстәкыйльлек;
- эшне башкаруга иҗади якын килү.

**8. Жюри әгъзалары:**

8.1 Эшләрне бәяләүне Бәйгенең жюри әгъзалары гамәлгә ашыра.

8.2 Бәйгене жюри рәисе җитәкли.

8.3. Жюриның барлык карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

8.4 Эшләр карау вакытында жюри өстәмә номинацияләр тәкъдим итә ала.

**9. Бәйгегә йомгак ясау һәм бүләкләү**

9.1 Бәйгедә җиңүчеләрне жюри билгели. Жюри карары ахыргы булып тора һәм яңадан каралмый.

9.2 Җиңүчеләр һәр яшь төркемендә һәм номинациядә 1, 2, 3 урыннар өчен дипломнар белән бүләкләнә. Призлы урыннарга кермәгән катнашучылар «Катнашкан өчен» дипломнар алачак. Дипломнар электрон рәвештә теркәлү карточкасында күрсәтелгән адреска җибәрелә.

**10. Бәйгене рекламау**

10.1 Бәйге массакүләм мәгълүмат чараларында, китапханә-челны.рф китапханә сайтында һәм «Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү китапханәсе» ВКонтакте төркеме битендә (https://vk.com/club137987058) яктыртылачак:

**Бәйгене уздыру урыны һәм элемтәләр өчен телефон:**

Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы филиалы: Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманова урамы, 48 йорт (Яңа шәһәр, 14/01). Телефон: 35-33-86; e-mail: cbs_filial12@mail.ru

Җаваплы: Аксуева А.З..

**Кушымта 1**

**Теркәлү карточкасы:**

«Гаиләмнең яраткан китабы» шәһәркүләм бәйгесенең теркәлү карточкасы:

Катнашучының ФИО____________________________________________________________

Катнашучының яше (тулы яше) __________________________________________________

Катнашучының укыган мәктәбе__________________________________________________

Эссенең исеме _______________________________________________________________

Бәйгедә катнашучының телефоны, электрон адресы (телефон, e-mail) _______________

Җитәкчесенең ФИО, телефоны (телефон, e-mail) ___________________________________

Бәйге шартлары белән таныштым һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза:

Дата ______________________ Подпись____________